**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «08» декабреннән № 492

«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апреленнән 203 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 31.08.2021 ел, 354 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Беренче абзацның 2 бүлегендәге 2.5 пунктында «13» санын «15» санына алмаштырырга;

1.2. Икенче абзацның 2 бүлегендәге 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өчтән алып җидегә кадәр савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бер тапкыр гына бирелә. Бер сыер саву аппаратына субсидия алганнан соң 1 ел узгач кына, элек булган сыерлар саны биш башка артса, икенче саву аппаратына субсидия бирелә. Ике сыер саву аппаратына субсидия алганнан соң 1 ел узгач кына, элек булган сыерлар саны биш башка артса, субсидия өченче саву аппаратына бирелә. Субсидияләү өч тапкыр һәм өчтән дә артык булмаган саву аппараты бирелә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов